РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 74

2021 елның 18 ноябре

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2021 елның 1 сентябрендәге 48 номерлы «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 86 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 23.1 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2021 елның 1 сентябрендәге 48 номерлы «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү турында» карарына (алга таба – карар) – түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 8 нче кушымтаның 2 нче пунктында

2 нче абзацта «10 процент» сүзләрен «25 процент» сүзләренә алмаштырырга, «бер тапкыр бирелә торган» сүзен төшереп калдырырга;

19 нчы кушымтаның 2 нче пунктындагы 2 нче абзацында «5 процент» сүзләрен «25 процент» сүзләренә алмаштырырга, «10 процент» сүзләрен «30 процент» сүзләренә алмаштырырга.;

23 нче кушымтаның 1 нче пунктындагы 2 нче пунктчасында «муниципаль хокукый актларда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә» сүзләрен «җирле үзидарә органнарының локаль актлары нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

карарга 19 нчы кушымтаның 1 нче пунктындагы 2 нче абзацы һәм 1 нче пунктындагы 2 нче абзацы үз көчен югалткан дип танырга.

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге, Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органнарына әлеге карарның үтәлешен тәэмин итәргә.

2. «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Бюджет һәм финанслар департаменты» муниципаль казна учреждениесенә әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге

карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2021 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Советының социаль-икътисадый үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы,
район Башлыгы урынбасары

А.В.Умников